РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

улица К.Маркса, дом 46,
город Чистополь, 422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

К.Маркс урамы, 46 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел.(84342) 5-13-38, тел/факс 5-13-38, E-mail: chistay@tatar.ru

***Постановление*** ***Карар***

20.02.2019 **Чистай шәһәре** № 31

“Муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яки өлешчә җирле билгеләнештәге юллар буйлап узучы маршрутлар буенча эре күләмле, авыр йөкләрне автомобиль ташуларына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең администртатив регламентын раслау турында”

Чистай шәһәр прокуратурасының муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 11.02.2019 елгы 02-08-02-2019нче номерлы протестын үтәү йөзеннән, 08.11.2007 елда кабул ителгән “Россия Федерациясендә автомомбиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы 257 нче номерлы Федераль законын, 27.07.2010 елда кабул ителгән “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210нчы номерлы Федераль законын,Татарстан Республикасының 03.08.2009 елда кабул ителгән “Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында”гы 43 нче номерлы законын, Транспорт министрлыгының 24.07 2012 елгы “Эре күләмле, авыр йөкләр ташучы транспорт чараларының автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итүенә махсус рөхсәт бирү Тәртибен раслау турында”гы 258 нче номерлы боерыгын, “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставын үтәү йөзеннән Чистай шәһәре башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яки өлешчә җирле билгеләнештәге юллар буйлап узучы маршрутлар буенча эре күләмле, авыр йөкләрне автомобиль ташуларына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең администртатив регламентын кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

2. Чистай шәһәре башкарма комитетының 27.07.2016 елгы “Муниципаль хезмәт күрсәтүнең администртатив регламентын раслау турында”гы 108нче номерлы карарын үз көчен югалтан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый-мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Шәһәр башкарма комитеты
җитәкчесе вазифаларын башкаручы А.В. Сашин.

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль
районының Чистай
шәһәре башкарма
комитеты карарына
нче кушымта
№____ _________2019 ел

**Муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яки өлешчә җирле билгеләнештәге юллар буйлап узучы маршрутлар буенча эре күләмле, авыр йөкләрне автомобиль ташуларына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең администртатив регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба –Регламент) муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яки өлешчә җирле билгеләнештәге юллар буйлап узучы маршрутлар буенча эре күләмле, авыр йөкләрне автомобиль ташуларына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын һәм тәртибен раслый (алга таба – муниципаль хезмәт).

1.2. Муниципаль хезмәтләр алучылар: физик һәм юридик затлар

1.3. Муниципаль хезмәтләр Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәре башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә (алга таба – шәһәр башкарма комитеты).

Муниципаль хезмәтне башкаручы - Чистай шәһәре башкарма комитетының ТКХ, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге (алга таба - Бүлек).

1.3.1. Шәһәр башкарма комитеты урнашкан урын: ТР, Чистай шәһәре, К.Маркс урамы, 46 нчы йорт

Бүлекнең урнашкан урыны: ТР, Чистай шәһәре, К.Маркс урамы, 46 нчы йорт

Эш графигы:

дүшәмбе- җомга: 8:00дән 17:00 сәгатькә кадәр;

шимбә, якшәмбе – ял көннәре.

Ял итү һәм туклану өчен вакыт эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнә.

Белешмәләр өчен телефон 8(84342) 5-04-60.

Керү шәхесне раслаучы документлар буенча.

1.3.2. Муниципаль районның “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдәге рәсми сайты адресы (алга таба – “Интернет”): (http:// chistopol.tatarstan.ru.).

1.3.3. Муниципаль хезмәт турындагы мәгълүматны алу мөмкинлекләре:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен шәһәр башкарма комитеты биналарында урнашкан муниципаль хезмәтләр турындагы визуаль һәм текст мәгълүматларыннан торган мәгълүмати стендлар чаралары буенча.

. 2) Муниципаль районның “Интернет” рәсми сайты чаралары белән (http:// chistopol.tatarstan.ru.).

3) Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi. tatar.ru/);

4) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) Бердәм порталында (http:// www.gosuslugi.ru/);

5) Шәһәр башкарма комитетында (Бүлектә):

телдән мөрәҗәгать иткәндә –шәхсән яки телефон буенча;

язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ алымы белән) – почта буенча кәгазьдә, электрон формада электрон почта аша.

1.3.4 Муниципаль хезмәтләр күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан муниципаль районның рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләүче шәһәр башкарма комитеты биналарының мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4.Муниципаль хезмәтләр күрсәтү түбәндәгеләр белән гамәлгә ашырыла:

06.10.2003 елда кабул ителгән "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 131нче номерлы Федераль закон ( алга таба -131нче номерлы Федераль закон) (РФның законнар җыентыгы, 06.10.2003, № 40, 3822 нче маддә).

08. 11. 2007 елда кабул ителгән "Россия Федерациясендә автомомбиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында"гы 257 нче номерлы Федераль закон ( алга таба -257нче номерлы Федераль закон) (РФның законнар җыентыгы, 12.11.2007, № 46, 5553 нче маддә).

27.07.2010 елда кабул ителгән "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында"гы 210нчы номерлы Федераль закон ( алга таба - 210нчы номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 нчы маддә);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 15.04.2011елгы "Автомобиль транспорты белән йөкләр ташу кагыйдәләрен раслау турында"гы 272 нче карары (алга таба – 272 нче Карар);

Транспорт министрлыгының 24.07 2012 елгы "Эре күләмле, авыр йөкләр ташучы транспорт чараларының автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итүенә махсус рөхсәт бирү Тәртибен раслау турында"гы 258 нче номерлы боерыгы ( алга таба –Тәртип) (Российская газета, №265, 16.11.2012 (кушымтасыз бастырылган);

Татарстан Республикасының 28.07.2004 елгы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 45нче номерлы законы (алга таба – 45 нче номерлы ТР законы) ( Татарстан Республикасы, №155-156, 03.08.2004);

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының "Чистай шәһәре" муниципаль берәмлегенең Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының "Чистай шәһәре" Советының 14.02.2014 елгы 28/6 нчы карары белән кабул ителгән Уставы (алга таба - Устав);

1.5. Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

авыр күләмле йөк – транспорт чарасы, аның массасы йөк белән һәм (яки) йөксез һәм (яки) күчәр массасы 272 нче Карарда китерелгән параметрларның берсеннән булса да артып китсә – Тәртип инструкциясе нигезендә йөк массасына һәм күләменә бәйле рәвештә билгеләнә:

1нче категория - транспорт чарасы, аның массасы йөк белән һәм (яки) йөксез һәм (яки) күчәр массасы, шулай ук күләмнәр биеклеге, киңлеге яки озынлыгы буенча 272 нче Карарда китерелгән параметрлардан артып китә, әмма 2нче категориягә карамый;

2нче категория – транспорт чарасы, аның эре күләмле йөк белән яки йөксез авырлык параметрлары 272 нче Карарда китерелгән авырлыкка тәңгәл килә;

эре күләмле йөк - транспорт чарасы, аның йөк белән яки йөксез күләмнәре биеклеге, киңлеге, озынлыгы буенча 272 нче Карар белән билгеләнгән күләмнәрнең берсеннән булса да артык булса;

йөк ташучы –юридик яки физик зат, алар эре күләмле яки авыр йөк ташуларны гамәлгә ашыра. Болар нинди милек формасы белән эшләүгә һәм нинди ведомствога каравына бәйсез булган оешмалар, һәм Россия Федерациясе гражданнары, гражданлыклары булмаган затлар, шулай ук халыкара оешмалар, чит ил гражданнары һәм юридик затлары, тиешле лицензияләре һәм серфитикатлаштырылган күчмә составлары булган;

техник хата - муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән хата (хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хаталар) һәм документларга (муниципаль хезмәтләр нәтиҗәсе) кертелгән белешмәләргә туры килмәү сәбәпле, документларга алар буенча кертелгән белешмәләрдәге хаталар.

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза астында (алга таба - гариза) муниципаль хезмәтләр күрсәтү турындагы сорау дип аңлашыла (27.07.2010 елгы 210 нчы Федераль законның 2 нче пунктының 2 нче маддәсе). Гариза стандарт бланкта тутырыла (1нче кушымта)

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исемлеге | Стандарт эчтәлегенә таләпләр | Муниципаль хезмәтне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1 Муниципаль хезмәтләр исемлеге. | Муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яки өлешчә җирле билгеләнештәге юллар буйлап узучы маршрутлар буенча эре күләмле, авыр йөкләрне автомобиль ташуларына рөхсәт бирү | 257 нче Федераль закон; Тәртип |
| 2.2. Җирле үзидарәнең турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче башкаручы-булүче органы исеме | Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре башкарма комитеты | БК турында нигезләмә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Гомуми кулланыштагы юллар буйлап эре күләмле һәм (яки) авыр йөкләрне автомобиль ташуларына рөхсәт (1нче кушымта);<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында хат | 257 нче Федераль закон; Тәртип |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итүнен зарурлыгын исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату вакыты, әгәр Россия Федерациясе законы тарафыннан аны туктату мөмкинлеге каралган булса.<br>Әгәр авыр күләмле | Гариза теркәлгән көннән ун эш көне дәвамында, транспорт чарасының маршрутын Дәүләт автоинспекциясе белән килештерү зарурлыгы булмаганда гариза теркәлгән көннән 15 эш көне дәвамында;<br>бер эш көне дәвамында оператив тәртиптә махсус рөхсәт биргән өчен дәүләт пошлинасын түләүне, авыр күләмле транспорт чарасы белән автомобиль юлларына китерелгән зыянны каплау түләүләрен раслаучы түләү документлары күчермәләрен тәкъдим итү мөмкинлеге белән. | 257 нче Федераль законның 41, 43нче пунктлары;<br>31нче маддә, 17 нче өлеш |

| | | |
|---|---|---|
| транспорт чарасы күчәренә көчәнеш рөхсәт ителгән көчәнештән ике процентка, әмма ун процenttан күбрәк түгел, артып китсә, шундый транспорт чарасының билгеләнгән даими маршруты буенча хәрәкәт итү өчен махсус рөхсәт, шул исәптән электрон формада, җиңеләйтелгән тәртиптә бирелә. | | |
| 2.5 Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәк булган документларның тулы исемлеге, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәт, аларны гариза бирүче тәкъдим итәргә тиеш, шул исәптән электрон формада, аларны бирү тәртибе | 1) Гариза (2нче кушымта);<br>2) Шәхесне раслаучы документлар;<br>3) Вәкилнең вәкаләтен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эшләсә);<br>4) транспорт чарасы документлары күчермәсе (транспорт чарасы паспорты яки транспорт чарасын теркәү турындагы таныклык), аңардан файдаланып эре күләмле һәм (яки) авыр йөкләр ташу планлаштырыла;<br>5) транспорт чарасы (автопоезд) схемасы, аңардан файдаланып эре күләмле һәм (яки) авыр йөкләр ташу планлаштырыла, шундый йөкне Тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә урнаштыру рәсеме беләп. Йөк ташуларда катнашуны планлаштыручы транспорт чарасы схемасында күчәрләр һәм алардагы тәгәрмәчләр саны, йөкне күчәрләр буенча бүлгәндә һәм күчәр озынлыгы буенча тигез бүлмәгән очракта күчәрләрнең һәм тәгәрмәчләрнең узара урнашуы – аерым тәгәрмәчләргә бүлү;<br>6) күрсәтелгән йөкне транспортта ташуга техник | Тәртипнең 8,9нчы пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | таләпләр турындагы белешмә. Дәүләт пошлинасын түләү турында белешмә. | |
| 2.6 Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә кирәк булган документларның тулы исемлеге, алар дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында һәм аларны гариза бирүче тәкъдим итәргә хаклы, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны бирү тәртибе; алар дәүләт органы, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында | Ведомствоара үзараэлемтә кысаларында була<br>ЕГРЮЛдан белешмә<br>ЕГРИПтан белешмә | |
| 2.7. Норматив-хокукый актлар белән каралган очракларда килештерү кирәк булган дәүләт оганнары (җирле үзидарә органнары) һәм аларның структур подразделениеләре исемлеге, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен таләп ителә һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче | Маршрут узучы юллар хуҗалары белән | |

| | | |
|---|---|---|
| башкарма власть органы тарафыннан гамәлгә ашырыла | | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | 1) Гаризага әлеге гаризага кул кую вәкаләте булмаган зат кул куйган;<br>2) гаризада Тәртипнең 8нче пункты белән билгеләнгән хәбәрләр юк;<br>3) әлеге Регламентның 2.5нче пунктында күрсәтелгән документлар бркетелмәгән. | Тәртипнең 12нче пункты |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яисә баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен сәбәпләр:<br>1) вәкаләтле органның Тәртип буенча тәкъдим ителгән маршрут буенча махсус рөхсәт бирү хокукы юк;<br>2) гаризада һәм документларда күрсәтелгән хәбәрләр транспортның һәм йөкнең техник характеристикаларына тәңгәл килми, шулай ук белдерелгән эре күләмле һәм (яки) авыр йөкләрне ташуга техник мөмкинлек юк;<br>3) бүленә торган йөкне ташу турындагы билгеләнгән таләпләр үтәлмәгән;<br>4) маршрутны килештергәндә белдерелгән маршрут буенча автомобиль юлларының техник торышы, ясалма корылмалар яки инженерлык коммуникацияләренең техник торышы уңаеннан белдерелгән техник характеристикалар белән, шулай ук юл хәрәкәте иминлеге таләпләре буенча йөк ташуны гамәлгә ашыру мөмкин булмавы билгеләнгән;<br>5) Гариза бирүче түбәндәгеләр белән килешми:<br>Тәртипнең 26нчы пункты нигезендә автомобиль юлының техник торышын бәяләү үткәрү;<br>автомобиль юлларын ныгыту яки автомобиль юлларын кисеп үтүче корылмалар һәм инженерлык | Тәртипнең 40нчы пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | коммуникацияләрен җиһазландыру буенча махсус чаралар кабул итү, автомобиль юлының техник торышын бәяләү үткәрү нигезендә һәм закон тарафыннан билгеләнгән очракларда;<br>6) гариза бирүче автомобиль юлларының техник торышын бәяләү, аларны ныгыту өчен түләмәгән, әгәр шундый эшләр гариза бирүче белән килештереп эшләнгән булса;<br>7) гариза бирүче автомобиль юлларын, аларның участокларын, шулай ук автомобиль юлларын кисеп үтүче корылмалар һәм инженерлык коммуникацияләрен җиһазландыру буенча махсус чаралар кабул иткән өчен түләмәгән, әгәр шундый эшләр гариза бирүче белән килештереп эшләнгән булса;<br>8) гариза бирүче авыр күләмле йөк ташучы транспорт чарасы белән автомобиль юлларына китерелгән зыянны каплау өчен түләү кертмәгән;<br>9) махсус рөхсәт бирү вакытына гаризаның төп нөсхәсе һәм автопоезд схемасы, транспорт чарасының расланган теркәлү документлары булмау, әгәр гариза һәм документлар вәкаләтле органга факс элемтәсе аша җибәрелгән булса;<br>10) гариза бирүче тарафыннан документлар тулы күләмдә бирелмәгән яисә бирелгән гаризаларда һәм документларда тулы булмаган һәм (яки) ялган мәгълүмат күрсәтелгән.<br>Рөхсәт бирүдән баш тарткан очракта гариза бирүчегә мәгүлүмат бирү срогы - гариза теркәлгәннән соң 4 эш көне. | |
| 2.10 Муниципаль | Дәүләт пошлинасы күләмнәре: | РФ НК 333.33нче маддәсенең |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтләр күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләүләр алу тәртибе, күләме һәм сәбәбе . | йөк ташучы транспорт чарасының автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итүенә махсус рөхсәт бирү ( халыкара автомобиль ташуларын гамәлгә ашыручы транспорт чарасыннан кала):<br>эре күләмле һәм (яки) авыр йөк– 1 600 сум | 111 нче өлеше. |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган түләүләр алу тәртибе, күләме һәм сәбәбе, алар шундый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны үз эченә алып | Тиешле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12 Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорауны биргән һәм шундый хезмәт нәтиҗәсен алган вакытта чиратта торуның максималь срогы | Чират булганда муниципаль хезмәт алуга гариза бирү – 15 минуттан артмый.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта торуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы соравын теркәү срогы, шул исәптән электрон формада | Гариза кергәннән соң бер көн дәвамында | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрнең көтү һәм кабул итү урынына, шул исәптән Россия | Муниципаль хезмәтләрне күрсәтү янгынга каршы һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган, документларны рәсмиләштерү өчен тиешле җиһазлар, мәгълүмат стендлары булган зданиеләрдә һәм биналарда гамәлгә ашырыла | |

| | | |
|---|---|---|
| Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законы нигезендә күрсәтелгән объектларга инвалидларның керүен тәэмин итүгә, визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматны урнаштыруга һәм рәсмиләштерү, аларны күрсәтү тәртибенә таләпләр | Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына каршылыксыз кереп-чыгуы тәэмин ителә (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә бер урыннан бер урынга күчеп йөрүе).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текст формасында һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып | |
| 2.15. Муниципаль хезмәтләрне алу мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчеләрнең вазифаи затлар белән үзара элемтәсе саны һәм аның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәтне дәүләт һәм муниипаль хезмәт күрсәтүнең күп функцияле үзәкләрендә, дәүләт һәм муниипаль хезмәт күрсәтүнең күп функцияле үзәкләренең читтәге эш урыннарында алу мөмкинлеге, муниипаль хезмәт күрсәтү барышы турындагы мәгълүматны, шул исәптән мәгълүмати- коммуникацион технологияләрдән файдаланып | Муниципаль хезмәтләрне алу мөмкинлеге күрсәткечләре:<br>Чистай муниципаль районының Чистай шәһәре башкарма комитеты (бүлек) биналарының җәмәгать транспорты йөри торган зоналарда урнашуы;<br>кирәкле белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итүне гамәлгә ашыручы биналарның җитәрлек санда булуы;<br>мәгълүмат стендларында, “Интернет” челтәрендәге http:// chistopol.tatarstan.ru мәгълүмат ресурсларында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең Бердәм порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>гариза бирүчеләрдән документлар кабул иткәндә һәм аларны биргәндә чиратлар булмау;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;<br>муниципаль хезмәтләр күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) | |

| | | |
|---|---|---|
| | шикаятьләр булмау;<br>муниципаль хезмәтләр күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр булмау.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау биргәндә һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алганда гариза бирүчеләрнең вазифаи затлар белән бер генә үзара элемтәсе күз уңында тотыла. Үзара элемтәнең дәвамлылыгы регламент белән билгеләнә.<br>Муниципаль хезмәтләрне дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ) күрсәткәндә консультацияне, документларны кабул итү һәм тапшыруны КФҮ белгече гамәлгә ашыра.<br>Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турындагы мәгълүматны район сайтында: http://chistopol.tatarstan.ru/., дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең Бердәм порталында, КФҮдә алырга мөмкин. | |
| 2.16. Муниципаль хезмәтне электрон формада бирү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәтләр алу тәртибе турындагы консультацияне Интернет-кабул итү аша электрон формада яки Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында алырга мөмкин.<br>Әгәр закон тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны электрон формада бирү каралган булса, гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/) яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең ( функцияләрнең) Бердәм порталы (http:// www.gosuslugi.ru/) аша бирелә. | |

3.Административ процедураларның составы, эзеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрдә, күпфункцияле үзәкләрнең читтәге эш урыннарында үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү үз эченә түбәндәге процедураларны ала:

1) гариза бирүче белән консультация үткәрү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара сорауларны формалаштыру һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен тапшыру.

3.1.2 Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелек блок-схемасы 4 нче кушымтада тәкъдим ителгән.

3.2. Гариза бирүчегә консультация күрсәтү

3.2.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәт алу тәртибе турында консультация алу өчен Бүлеккә шәхсән, телефон аша һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хаклы.

Бүлек белгече гариза бирүче белән консультация үткәрә, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм муниципаль хезмәтләр алу өчен башка сораулар буенча һәм әгәр кирәк булса гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Әлеге пункт белән урнаштырылучы процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм рөхсәт алу өчен башка мәсьәләләр буенча консультация.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1.Гариза бирүче шәхсән үзе, ышанычлы кеше яки КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтүләрен сорап язмача гариза бирә һәм Бүлеккә әлеге Регламентның 2.5 нче пункты белән каралган документларны тапшыра. Документлар читтәге эш урыннары аша да бирелергә мөмкин. Читтәге эш урыннарының исемлеге 5 нче кушымтада китерелгән.

Муниципаль хезмәтне электрон формада алу турындагы гариза Бүлеккә электрон почта яки Интернет-кабул итү аша җибәрелә.Электрон формада кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.3.2. Бүлекнең гаризаларны кабул итүне алып баручы белгече түбәндәгеләрне башкара:

гариза бирүченең шәхесен ачыклый;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә ( ышаныч кәгазе буенча булса);

әлеге Регламентның 2.5нче пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерү;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерү (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда бетерүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм башка төзәтүләр булмаска тиеш).

Дәгъвалар булмаган очракта Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаны кабул итә һәм махсус журналда терки;

гариза бирүчегә документларны кабул итү тамгасы белән тапшырылган документларның исемлеге күчермәсен, бирелгән керүче номерны, муниципаль хезмәт күрсәтү көнен һәм вакытын тапшыра;

гаризаны Башкарма комитет җитәкчесенә карауга җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләр булган очракта Бүлекнең гаризаларны кабул итүне алып баручы белгече гариза бирүчегә гариза теркәү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм аңа документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган сәбәпләрне язма рәвештә аңлатып тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнүче процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

гаризаны һәм документларны 15 минут эчендә кабул итү;

гариза кергәннән соң аны бер көн дәвамында теркәү.

Процедура нәтиҗәсе: Башкарма комитет җитәкчесенә карауга җибәрелгән гаризаны кабул итү һәм теркәү яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3.Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе гаризаны карый, башкаручыны билгели һәм гаризаны Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнүче процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан алып бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: башкаручыга җибәрелгән гариза.

3.4.Ведомствоара сорауларны формалаштыру һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү

3.4.1.Бүлек белгече электрон формада ведомствоара электрон үзараэлемтә системасы чаралары буенча дәүләт пошлинасын түләү турында белешмә бирү турындагы сорауны җибәрә.

Әлеге пункт нигезендә урнаштырыла торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан алып бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: җибәрелгән сорау.

3.4.2. Мәгълүматлар куючы белгечләр ведомствоара электрон үзараэлемтә системасы аша кергән сораулар нигезендә соратыла торган документларны (мәгълүматны) бирәләр яки муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәк булган документ һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында белдерү җибәрәләр (алга таба – баш тарту турында белдерү).

Әлеге пункт белән билгеләнүче процедуралар ведомствоара сорауның документ яки мәгълүмат бирүче органга яки оешмага керү көненнән алып биш көн дәвамында гамәлгә ашырыла, әгәр Федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары тарафыннан ведомствоара сорауга җавап әзерләү һәм җибәрү сроклары билгеләнмәгән һәм федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары белән кабул ителмәгән булса.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән документлар (белешмә) яисә кире кагу турында белдерү.

3.5 Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1.Бүлек белгече гамәлгә ашыра:

гаризага беркетелгән документларда булган хәбәрләрне тикшерә;

муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.9 нчы пункты белән каралган сәбәпләрнең булу-булмавын тикшерә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен сәбәпләр булган очракта Бүлек белгече рөхсәт бирүгә сәбәбе күрсәтелгән кире кагу проектын әзерли ( алга таба – сәбәбе күрсәтелгән кире кагу).

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен сәбәпләр булмаган очракта Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

авыр йөкләрне, эре күләмле йөкләрне автомобиль ташуларына рөхсәт проектын әзерли ( алга таба – рөхсәт);

рөхсәт проектын гомуми бүлек начальнигы белән килештерә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: гомуми бүлек начальнигына килештерүгә җибәрелгән рөхсәт проекты яки сәбәбе күрсәтелгән кире кагу.

3.5.2 Гомуми бүлек начальнигы кергән рөхсәт проектын яки сәбәбе күрсәтелгән кире кагуны килештерү һәм шәһәр башкарма комитеты җитәкчесенә имза куюга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: шәһәр башкарма комитеты җитәкчесенә имза куюга җибәрелгән рөхсәт проекты яки сәбәбе күрсәтелгән кире кагу.

3.5.3 Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе рөхсәт проектын яки сәбәбе күрсәтелгән кире кагуны раслый һәм Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән имза куелган рөхсәт яки сәбәбе күрсәтелгән кире кагу.

3.6. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен тапшыру

3.6.1. Бүлек белгече кабул ителгән карар турында гариза бирүчегә телефон һәм (яки) электрон почта аша хәбәр итә һәм рөхсәтне яки сәбәбе күрсәтелгән кире кагу бирә яисә почта аша җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар тормышка ашырыла:

15 минут эчендә - гариза бирүче шәхсән үзе килсә;

әлеге Регламентның 3.5.3 нче пунктчасы белән каралган алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла, әгәр җавап почта аша җибәрелсә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) рөхсәт яки сәбәбе күрсәтелгән кире кагу.

3.7.Муниципаль хезмәтне МФҮ аша күрсәтү.

3.7.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәт алу өчен МФҮкә, МФҮнең читтәге эш урынына мөрәҗәгать итәргә хаклы.

3.7.2. МФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү МФҮнең билгеләнгән тәртиптә расланган эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.7.3. Муниципаль хезмәт алуга МФҮтән документлар кергәндә процедуралар әлеге регламентның 3.3 - 3.5нче пунктлары нигезендә тормышка ашырыла. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе МФҮгә җибәрелә.

3.8.Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта техник хаталар табылган очракта гариза бирүче Бүлеккә түбәндәгеләрне тәкъдим итә:

техник хатаны төзәтү турында гариза (6 нчы кушымта);

муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак, гариза бирүчегә тапшырылган, техник хата күрсәтелгән документ;

техник хата булуын раслаучы юридик көче булган документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны гариза бирүче (аның вәкаләтле вәкиле) шәхсән үзе яисә почта аша (шул исәптән электрон почтадан файдаланып) яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең Бердәм порталы яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк аша тапшыра.

3.8.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, тәкъдим ителгән документлар белән гаризаны терки һәм Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гариза теркәлгән вакыттан алып бер көн дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә карауга җибәрелгән гаризаны кабул итү һәм теркәү .

3.83. Бүлек белгече документларны карый һәм хезмәт нәтиҗәсе булган документка төзәтүләр кертү максатында әлеге Регламентның 3.5нче пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм гариза бирүчегә ( аның вәкаләтле вәкиленә) шәхсән кул куеп төзәтелгән документны тапшыра, гариза бирүчедән (аның вәкаләтле вәкиленнән) техник хата киткән документның төп нөсхәсен ала, яки гариза бирүче адресына почта аша

( электрон почта чаралары аша) техник хата киткән документның төп нөсхәсен Бүлеккә тапшырган очракта, документ алу мөмкинлеге булу турында хат җибәрә

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура техник хатаны тапканнан яки теләсә кайсы кызыксындырылган заттан җибәрелгән хата турында гариза алганнан соң өч көн дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

4. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм контрольдә тоту алымы

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына контроль үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукын бозуны ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедурасын үтәүгә тикшерү үткәрүне, җирле үзидарә органының вазифаи затлары эшенә (чара күрмәүләренә) карарлар әзерләүне ала.

Административ процедураларны үтәүне күзәтү өчен контроль алымнары булып торалар:

1) муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Проектларны визалау тикшерү нәтиҗәсе булып тора;

2) эш производстволарын алып баруга билгеләнгән тәртиптә тикшерүләр уздыру;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедурасын үтәүгә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр уздыру.

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органының яртыеллык яки берьеллык эш планнары нәтиҗәсендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр үткәргәндә муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) яки гариза бирүченең төгәл бер мөрәҗәгате буенча каралырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндәге гамәлләрне кылуга контрольлек итү максатында Башкарма комитет җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча билгеләнгән административ процедуралар эшенең эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контрольне Чистай шәһәре башкарма комитет җитәкчесе урынбасары, ул муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшләрне оештыру өчен җаваплы, шулай ук инфраструктура үсеше бүлеге белгечләре гамәлгә ашыра.

4.3. Агымдагы контрольне тормышка ашыручы вазифаи затларның исемлеге җирле үзидарә органының структур подразделениеләре турындагы нигезләмәләр һәм вазифаи регламентлар белән билгеләнә.

Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланганда гаепле затлар Россия Федерациясе законы нигезендә җавапка тартыла.

4.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен үзвакытында карамау өчен җаваплы.

Җитәкче урынбасары әлеге Регламентның 3нче бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне үзвакытында һәм (яки) тиешенчә башкармаулары өчен җаваплы.

Вазифаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кулланылучы (гамәлгә ашырылучы) карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) өчен Закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә җавап тоталар.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан муниципаль хезмәт күрсәтүгә контроль муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр башкарма комитеты (бүлеге) эшчәнлегенең ачыклыгы чаралары белән гамәлгә ашырыла.

## 5. Муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазифаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) дәгъва белдерү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәтләр алучылар шәһәр башкарма комитетына муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы шәһәр башкарма комитеты хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына ) судка кадәрге (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерергә хаклылар.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирүченең соравын теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр башкарма комитетының норматив-хокукый актлары белән каралмаган документларны таләп итү;

4) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр башкарма комитетының норматив-хокукый актлары белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту, әгәр баш тарту нигезләре федераль законнар һәм Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр башкарма комитетының алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары белән каралмаган булса.

6) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр башкарма комитетының норматив-хокукый актлары белән каралмаганда, түләү таләп итү;

7) шәһәр башкарма комитетының, шәһәр башкарма комитетының вазифаи затының муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда киткән хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуы.

8) дәүләт яки муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срокларын һәм тәртибен бозу;

9) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату, әгәр туктату сәбәпләре федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар тарафыннан каралмаган булса. Күрсәтелгән очракта гариза бирүченең судка кадәрге (судтан тыш) күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирүе мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелүче күпфункцияле үзәккә дәүләт яки муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса;

10) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү яисә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү. Күрсәтелгән очракта гариза бирүченең судка кадәрге (судтан тыш) күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирүе мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелүче күпфункцияле үзәккә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрен тулы күләмдә күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса.

5.2. Шикаять язма формада кәгазьдә яки электрон формада бирелергә мөмкин. Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәреннән файдаланып, Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр башкарма комитетының рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасының Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелергә, гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3 Шикаятьне карау срогы - аны теркәгәннән соң 15 эш көне дәвамында. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгыш язуларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга шикаять белдерелсә – аны теркәгәннән соң биш эш көне дәвамында.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән хезмәт күрсәтүче орган, хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының исеме яки муниципаль хезмәткәрнең исеме;

2) гариза бирүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы әгәр булса), яшәү урыны турында белешмә, шулай ук элемтә өчен телефон номеры, электрон почта адресы (әгәр булса) һәм почта адресы, аның буенча гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиеш;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү турында белешмә;

4) гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең, карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән килешмәвен нигезләүче дәлилләр.

5.5 Шикаятькә анда язылган хәлләрне раслаучы документларның күчермәләре беркетелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа беркетелгән документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятькә аны бирүче муниципаль хезмәт алучы имза куя.

5.7.Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү, гариза бирүчегә акчаны кире кайтару формасында канәгатьләндерелә, әгәр акча алу Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары белән шулай ук башка формаларда каралмаган булса ;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Карарны кабул иткән көннән соң килә торган көннән соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача формада һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән җавап җибәрелә.

1) шикаятьне канәгатьләндерергә кирәк дип тапкан очракта, гариза бирүчегә җавапта дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күп функцияле үзәк яисә оешма тарафыннан башкарылган гамәлләр турында мәгълүмат дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган бозуларны тиз арада бетерү максатында мәгълүмат бирелә, шулай ук китергән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм дәүләт яки муниципаль хезмәт алу максатында гариза бирүчегә алга таба нәрсә эшләргә кирәклеге турында мәгълүмат күрсәтелә;

2) шикаятьне канәгатьләнерлек дип тапмаган очракта гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында аргументлаштырылган аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки шикаятьне карау буенча вәкаләтләре булган вазифаи затның, хезмәткәрнең җинаятьләре ачыкланса, тиз арада булган материаллар прокуратура органнарына җибәрелә.